Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Колай авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

12 март, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 20 номерлы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өчен уңай шартларга район халкының хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты гавами тыңлауларны оештыручы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 28 мартыннан да соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская